# КАРАР

**“28” ноябрь 2023 ел** **№ 6**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Югары Мәтәскә авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 28 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

« Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Югары Мәтәскә территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 75 яшьтән узган гражданнардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы?:

**1. Җирлектәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

-юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш белән каплау Югары Мәтәскә авылы Азин урамы;

**2. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:**

-Югары Мәтәскә авылында скважина өчен насос сатып алу-1 данә.

« ӘЙЕ» “КАРШЫ”

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) 197 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 100 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 96 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 4 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл

җирлеге Югары Мәтәскә авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Югары Мәтәскә территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 75 яшьтән узган гражданнардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы?:

**1. Җирлектәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

-юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш белән каплау Югары Мәтәскә авылы Азин урамы;

**2. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:**

-Югары Мәтәскә авылында скважина өчен насос сатып алу-1 данә.

ӘЙЕ» - “КАРШЫ“-

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. . Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Югары Мәтәскә авылы, Азин урамы, 31 йорты адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Лутфуллин Ф.Ф.